ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап турында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә, югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә һәм аларны яңадан әзерләүгә, Татарстанның эре предприятиеләре белән берлектә яңа перспектив проектларны үстерүгә һәм гамәлгә ашыруга, республиканың сәламәтлек саклау һәм мәгариф системаларының алгарышлы үсеш бурычларына ярдәм итүгә керткән өлешен, университетның Татарстан Республикасы фәнни-инновацион куәтен ныгытуда әйдәп баручы булуын билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисапны хупларга.

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында үсеш программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе                                        Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 187-VII ДС